ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.03.2021 с.Старое Дрожжаное № 109

Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслау һәм эшләү Тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарына таянып, «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибе турында» Башкарма комитет карары нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 03 сентябрендәге 380 номерлы (12.03.2021 № 90 редакциясендә) карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентының 3 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1 пунктта:**

**дүртенче абзацны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «гражданнарны теркәү турында белешмәләр;»;

**унсигезенче абзацны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чит дәүләтнең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклыклар һәм аларның рус теленә нотариаль таныкланган тәрҗемәсе;»;

**егерме беренче абзацны** төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле **абзац өстәргә**:

«гражданлык хәле актларын теркәү органнары яисә Россия Федерациясенең консул учреждениеләре тарафыннан бирелгән уллыкка алу турында таныклыклар;».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары И.С. Бикчуровка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Д.А. Сатдинов